**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

07.04.2022　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№413

Территорияне планлаштыру буенча
документлар эшләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары нигезендә «Символ Про» ЧҖҖнең территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Символ Про» ҖЧҖенең Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә юл-урам челтәрен төзү» объектының планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын үз акчалары исәбеннән әзерләү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.
2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә физик һәм юридик затларның территорияләрне планлаштыру һәм межалау проектын әзерләү тәртибе, әзерләү сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрен кабул итәргә һәм карарга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Р. Хәмзин